**2022 елда квалификация имтиханы һәм аттестация үткәргәндә тест тапшыру өчен сораулар исемлеге**

«Муниципаль хезмәт» блогы буенча тест тапшыруга әзерләнү һәм тестны уңышлы узу өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ Федераль законны, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ Татарстан Республикасы Законын өйрәнергә кирәк.

Муниципаль хезмәт буенча сораулар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. күрсәтелгән законнарның (җайга салу предметы, муниципаль хезмәт төшенчәсе һәм башкалар) гомуми нигезләмәләрен белү;
2. муниципаль хезмәт вазыйфалары (вазыйфаларның классификацияләре, вазыйфалар биләүгә квалификация таләпләре);
3. муниципаль хезмәткәрләрнең класслы чиннары (классификация, класслы чин бирүнең нигезлелеге һәм тәртибе);
4. муниципаль хезмәткәрнең төп хокуклары һәм бурычлары;
5. муниципаль хезмәт белән бәйле төп тыюлар һәм чикләүләр;
6. муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган төп гарантияләр;
7. муниципаль хезмәткә урнашучы гражданнарга таләпләр;
8. муниципаль хезмәт һәм дәүләт гражданлык хезмәтендә үзара элемтә;
9. эш (хезмәт) вакыты һәм ял вакытының, эш (хезмәт) вакытының дәвамлылыгы, өстәмә ялның дәвамлылыгы һәм башкалар);
10. муниципаль хезмәткәрнең квалификациясен күтәрү, аттестация үткәрү;
11. квалификация имтиханы (нинди очракларда үткәрелә);
12. муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүнең чик яше.

«Коррупциягә каршы тору» блогы буенча тест тапшыруга әзерләнү һәм аны уңышлы тапшыру өчен «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законын өйрәнергә кирәк.

Коррупциягә каршы тору буенча сораулар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) коррупциягә каршы тору турындагы законнарның төп төшенчәләре һәм нормалары;

2) муниципаль вазыйфага билгеләнгәндә гражданның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны бирү бурычы;
3) муниципаль хезмәткәрләрнең коррупцион хокук бозулар кылуы өчен җаваплылыгы;

1. коррупцияне профилактикалау;
2. коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча эшләү тапшырылган дәүләт хакимияте органнары;
3. коррупциягә каршы стандарт;
4. дәүләт яки муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан әлеге граждан белән хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү төзегәндә кертелә торган чикләүләрне үтәргә тиешле сроклар.

«Конституция» блогы буенча тест тапшыруга әзерләнү һәм аны уңышлы тапшыру өчен Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен өйрәнергә кирәк.

Конституция буенча сораулар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. конституцион төзелеш нигезләре;
2. Россия Федерациясе гражданлыгы;
3. Россия Федерациясендә кеше һәм гражданнар хокуклары һәм ирекләре гарантияләре;
4. Россия Федерациясе гражданнарының конституцион хокуклары һәм бурычлары;
5. Россия Федерациясенең барлык территориясендә нинди норматив хокукый актлар өстенлекле санала;
6. Россия Федерациясендә дәүләт хакимияте бүленеше;
7. Россия Федерациясе субъекты статусы
8. Россия Федерациясе Президенты
9. Федераль Җыенның палаталары;
10. Дәүләт Думасының вәкаләтләре срогы;
11. Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе кем тарафыннан билгеләнә;
12. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтләре срогы;
13. Россия Федерациясе законнары ничек кабул ителә (үз көченә керә һәм башкалар).

«Җирле үзидарә» блогы буенча тест тапшыруга әзерләнү һәм аны уңышлы тапшыру өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми

принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставын өйрәнергә кирәк.

Җирле үзидарә турындагы законнар, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы буенча сораулар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге статусы, муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү;
2. җирле үзидарәнең хокукый нигезе;
3. муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары;
4. вәкаләтләр, шәһәр Хакименең вәкаләтләре срогы;
5. вәкаләтләр, Шәһәр Советының вәкаләтләре срогы;
6. муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләре;
7. җирле референдум, муниципаль сайлаулар;
8. җәмәгать тыңлаулары, гражданнардан сораштыру, гражданнар җыелышлары;
9. муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасы;
10. рәсми бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) төрләре, тәртибе һәм муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе;
11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә.

Рус теле блогы буенча тест тапшыруга әзерләнү һәм аны уңышлы тапшыру өчен дөрес язу кагыйдәләрен, пунктуация һәм стилистиканы өйрәнергә кирәк.